КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 26 июль

г.Казань

№ 720

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә күпләп килгән Украина гражданнарына һәм Украина территориясендә даими яшәгән гражданлыгы булмаган затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын компенсацияләү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1051 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә күпләп килгән Украина гражданнарына һәм Украина территориясендә даими яшәгән гражданлыгы булмаган затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын компенсацияләү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1051 нче карарына (Татарстан Республи-

касы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 19 октябрь, 784 нче; 2017 ел, 28 декабрь, 1066 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә күпләп килгән Россия Федерациясе гражданнарына, Украина гражданнарына, Донецк Халык Республикасы гражданнарына, Луганск Халык Республикасы гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын һәм чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затларга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затларга һәм әлеге затлар белән бергә килгән аларның гаилә әгъзаларына мәҗбүри медицина тикшерүен үткәрү чыгымнарын компенсацияләү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында»;

преамбуланы, 1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә күпләп килгән Россия Федерациясе гражданнарына, Украина гражданнарына, Донецк Халык Республикасы гражданнарына, Луганск Халык Республикасы гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Россия Федерациясе территориясендә медицина ярдәме күрсәтү һәм аларга медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын һәм чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затларга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затларга һәм әлеге затлар белән бергә килгән аларның гаилә әгъзаларына мәҗбүри медицина тикшерүен үткәрү чыгымнарын федераль бюджет акчасы исәбеннән компенсацияләү турында» 2014 ел, 31 октябрендәге 1134 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә күпләп килгән Россия Федерациясе гражданнарына, Украина гражданнарына, Донецк Халык Республикасы гражданнарына, Луганск Халык Республикасы гражданнарына һәм гражданлыгы булма-

ган затларга Татарстан Республикасы Сзламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары тарафыннан медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын һәм чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затларга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затларга һәм әлеге затлар белән бергә килгән аларның гаилә әгъзаларына мәҗбүри медицина тикшерүен үткәрү чыгымнарын компенсацияләү федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар (алга таба – чыгымнарны компенсацияләү, башка бюджетара трансфертлар) исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә күпләп килгән Россия Федерациясе гражданнарына, Украина гражданнарына, Донецк Халык Республикасы гражданнарына, Луганск Халык Республикасы гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын һәм чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затларга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затларга һәм әлеге затлар белән бергә килгән аларның гаилә әгъзаларына мәҗбүри медицина тикшерүен үткәрү чыгымнарын компенсацияләү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен;

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә күпләп килгән Россия Федерациясе гражданнарына, Украина гражданнарына, Донецк Халык Республикасы гражданнарына, Луганск Халык Республикасы гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын һәм чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затларга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затларга һәм әлеге затлар белән бергә килгән аларның гаилә әгъзаларына мәҗбүри медицина тикшерүен үткәрү чыгымнарын компенсацияләү өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы дәүләт медицина оешмаларына субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен.»;

әлеге карар белән расланган Украина территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә күпләп килгән Украина гражданнарына һәм Украина территориясендә даими яшәгән гражданлыгы булмаган затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын компенсацияләү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә күпләп килгән Россия Федерациясе гражданнарына, Украина гражданнарына, Донецк Халык Республикасы гражданнарына, Луганск Халык Республикасы гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын һәм чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затларга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затларга һәм әлеге затлар белән бергә килгән аларның гаилә әгъзаларына мәҗбүри медицина тикшерүен үткәрү чыгымнарын компенсацияләү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу Тәртип, Халык төркемнәре һәм амбулатор дәвалаганда дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр табиблар рецептлары буенча түләүсез җибәрелә торган авырулар категорияләре исемлеге (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Медицина сәнәгатен үстерүгә дәүләт ярдәме, халыкны һәм сәламәтлек саклау учреждениеләрен дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр белән тәэмин итүне яхшырту турында» 1994 елның 30 июлендәге 890 номерлы карарына 1 нче кушымта) нигезендә халыкка җибәрелә торган дару препаратлары белән тәэмин итүне кертеп, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары (алга таба – медицина оешмалары) тарафыннан ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме, беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүгә, шулай ук гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына кертелгән авырулар һәм хәлләр булганда кичектергесез формада махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез

тәртиптә күпләп килгән Россия Федерациясе гражданнарына, Украина гражданнарына, Донецк Халык Республикасы гражданнарына, Луганск Халык Республикасы гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга алар мәҗбүри медицина иминияте полисын яисә полисны рәсмиләштерүнераслый торган һәм иминләштерелгән очрак булганда иминләштерелгән затка медицина оешмалары тарафыннан түләүсез медицина ярдәме күрсәтү хокукын таныклый торган вакытлы таныклык алганга кадәр эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкаларын ясауга һәм чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затларга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затларга һәм әлеге затлар белән бергә килгән аларның гаилә әгъзаларына мәҗбүри медицина тикшерүен үткәрүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләү компенсацияләү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) файдалану механизмын билгели.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү белән билгеләнгән формада һәм срокларда түбәндәгеләрне урнаштыра:

а) өстәп финанслау максаты белән башка бюджетара трансфертлар бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап;

б) башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап.»;

әлеге карарга Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә күпләп килгән Россия Федерациясе гражданнарына, Украина гражданнарына, Донецк Халык Республикасы гражданнарына, Луганск Халык Республикасы гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын һәм чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затларга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затларга һәм әлеге затлар белән бергә килгән аларның гаилә әгъзаларына мәҗбүри медицина тикшерүен үткәрү чыгымнарын компенсацияләү өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы дәүләт медицина оешмаларына субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2014 ел, 29 декабрь, 1051 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 26 июль, 720 нче
карары редакциясендә)

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә күпләп килгән Россия Федерациясе гражданнарына, Украина гражданнарына, Донецк Халык Республикасы гражданнарына, Луганск Халык Республикасы гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын һәм чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затларга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затларга һәм әлеге затлар белән бергә килгән аларның гаилә әгъзаларына мәҗбүри медицина тикшерүен үткәрү чыгымнарын компенсацияләү өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы дәүләт медицина оешмаларына субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү
тәртибе

1. Бу Тәртип Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәгән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә кичектергесез тәртиптә күпләп килгән Россия Федерациясе гражданнарына, Украина гражданнарына, Донецк Халык Республикасы гражданнарына, Луганск Халык Республикасы гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле булган чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын һәм чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затларга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затларга һәм әлеге затлар белән бергә килгән аларның гаилә әгъзаларына (алга таба – шул ук эзлеклелектә гражданнар һәм гражданлыгы булмаган затлар, медицина оешмалары) мәҗбүри медицина тикшерүен үткәрү чыгымнарын компенсацияләү өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган, бюджет һәм

автоном учреждениеләр булган дәүләт медицина оешмаларына субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү күләмен һәм шартларын билгели.

Бу Тәртиптә чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затлар, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затлар һәм әлеге затлар белән бергә килгән аларның гаилә әгъзалары дип гражданнар һәм гражданлыгы булмаган затлар аңлашыла.

Субсидияләр Халык төркемнәре һәм амбулатор дәвалаганда дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр табиблар рецептлары буенча түләүсез җибәрелә торган авырулар категорияләре исемлеге (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Медицина сәнәгатен үстерүгә дәүләт ярдәме, халыкны һәм сәламәтлек саклау учреждениеләрен дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр белән тәэмин итүне яхшырту турында» 1994 елның 30 июлендәге 890 номерлы карарына 1 нче кушымта) нигезендә халыкка җибәрелә торган дару препаратлары белән тәэмин итүне кертеп, медицина оешмалары тарафыннан ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме, беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүгә, шулай ук гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына кертелгән авырулар һәм хәлләр булганда кичектергесез формада махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә, Россия Федерациясе гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга алар мәҗбүри медицина иминияте полисын яисә полисны рәсмиләштерүне раслый торган һәм иминләштерелгән очрак булганда иминләштерелгән затка медицина оешмалары тарафыннан түләүсез медицина ярдәме күрсәтү хокукын таныклый торган вакытлы таныклык алганга кадәр эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкаларын ясауга һәм чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затларга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затларга һәм әлеге затлар белән бергә килгән аларның гаилә әгъзаларына мәҗбүри медицина тикшерүен үткәрүгә (алга таба – медицина ярдәме) бәйле чыгымнарны компенсацияләү компенсацияләү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән бирелә.

2. Субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе:

2.1. Субсидия алу өчен медицина оешмалары Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидия бирү кирәклеген нигезләүне үз эченә алган аңлатма язуын (субсидия суммасының исәп-хисап нигезләвен кертеп) тапшыра.

2.2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бу Тәртипнең 2.1 пунктчасында күрсәтелгән документларны алган көннән биш эш көне эчендә медицина оешмасы тарафыннан тапшырылган документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында йә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Медицина оешмасына субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

тапшырылган документларның бу Тәртипнең 2.1 пунктчасында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

медицина оешмасы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

2.3. Медицина оешмасына бирелә торган субсидия күләме (Si) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = C + З + O + R,$$

монда:

C – гражданнарга һәм гражданлыгы булмаган затларга күрсәтелгән медицина ярдәменең кыйммәте сум;

З – гражданнарга һәм гражданлыгы булмаган затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнары, сум;

O – гражданнарны һәм гражданлыгы булмаган затларны дарулар белән тәэмин итү чыгымнары, сум;

R – чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затларга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затларга һәм әлеге затлар белән килгән аларның гаилә әгъзаларына мәҗбүри медицина тикшерүен үткәрү чыгымнары, сум.

Гражданнарга һәм гражданлыгы булмаган затларга күрсәтелгән медицина ярдәменең кыйммәте (C) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$C = \Sigma\ (V_i \times N_i),$$

монда:

Vi – тиешле медицина ярдәме төренең күләме;

Ni – тиешле елга Мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасы буенча медицина ярдәме өчен түләү турында тариф килешүендә һәм тиешле елга медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша нигездә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән күрсәтелгән медицина ярдәме тарифларын һәм аңа түләү тәртибен билгеләү турындагы тариф килешүендә билгеләнгән тиешле медицина ярдәме төре күләме берәмлеге, югары технологияле медицина ярдәменең тиешле профиле төрләре (ысуллары) буенча бер пациентны дәвалау кыйммәте, сум.

Гражданнарга һәм гражданлыгы булмаган затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнары (З) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$З = \Sigma\ (P_i \times M_i),$$

монда:

Pi – эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән тиешле профилактика прививкалары төрләре ясалган гражданнар һәм гражданлыгы булмаган затлар саны;

Mi – эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән тиешле профилактика прививкасы төрен бер кешегә ясауның тиешле елга Мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасы буенча медицина ярдәменә түләү турында тариф килешүендә билгеләнгән кыйммәте, сум.

Гражданнарны һәм гражданлыгы булмаган затларны дару препаратлары белән тәэмин итү чыгымнары (O) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$O = \Sigma (L_i \times T_i),$$

монда:

Li – Халык төркемнәре һәм амбулатор дәвалаганда дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр табиблар рецептлары буенча түләүсез җибәрелә торган авырулар категорияләре исемлеге (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Медицина сәнәгатен үстерүгә дәүләт ярдәме, халыкны һәм сәламәтлек саклау учреждениеләрен дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр белән тәэмин итүне яхшырту турында» 1994 елның 30 июлендәге 890 номерлы карарына 1 нче кушымта) нигезендә халыкка җибәрелә торган тиешле авырулар категориясе өчен дару препаратлары язып бирелгән һәм җибәрелгән гражданнар һәм гражданлыгы булмаган затлар саны;

Ti – бер кешегә тиешле авырулар категориясе өчен фармацевтика базары бәяләренең уртача базар дәрәҗәсеннән һәм житештерүчеләрнең яшәү өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратларына теркәлгән бәяләреннән чыгып билгеләнә торган дару препартлары кыйммәте, сум.

Чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затларга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затларга һәм әлеге затлар белән килгән аларның гаилә әгъзаларына мәҗбүри медицина тикшерүен үткәрү чыгымнары (R) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$R = \Sigma (O_i \times B_i),$$

монда:

Qi – чынлыкта качкын дип тану турындагы үтенечнамәне карау турында таныклык алган затлар, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында гариза тапшырган затлар һәм әлеге затлар белән килгән аларның гаилә әгъзалары саны;

Bi – тиешле елга Мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасы буенча медицина ярдәме өчен түләү турында тариф килешүендә һәм тиешле елга медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша нигездә бер ка-

наллы финанслауны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән күрсәтелгән медицина ярдәме тарифларын һәм аңа түләү тәртибен билгеләү турындагы тариф килешүендә билгеләнгән тиешле медицина ярдәме төрләре буенча бер кешегә медицина тикшерүен үткәрү кыйммәте, сум.

2.4. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм медицина оешмасы, «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзи, анда түбәндәге нигезләмәләр бирелә:

субсидия бирү максатлары;

субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткече;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү чаралары планы;

субсидия күләме;

субсидия күчерү сроклары (графигы);

хисаплылыкны бирү сроклары;

медицина оешмасы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

килешүгә үзгәрешләр кертү (шул исәптән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына субсидия бирү өчен элегрәк җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметелгән очракта) нигезләре һәм тәртибе;

берьяклы тәртиптә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карары буенча килешүне вакытыннан алда , шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә туктату өчен нигезләр:

медицина оешмасын үзгәртеп оештыру (кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш) яки бетерү;

медицина оешмасы тарафыннан бу Тәртип һәм (яки) килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатлары һәм шартлары бозылу;

медицина оешмасы тарафыннан килешүне берьяклы тәртиптә өзүне тыю.

Кирәк булганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм медицина оешмасы, «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү яки килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

2.5. Килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 нче көненә медицина оешмасы туры килергә тиешле таләп – медицина оешмасының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары булмау.

2.6. Субсидия бирү нәтиҗәсе – субсидия бирелгән елның 31 декабренә субсидия акчасы исәбеннән медицина ярдәме күрсәтү планлаштырылган гражданнарның һәм гражданлыгы булмаган затларның гомуми санында субсидия акчасы исәбеннән медицина ярдәме күрсәтелгән гражданнар өлеше һәм гражданлыгы булмаган затлар өлеше кимендә 100 процент.

2.7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы субсидияне килешүдә каралган срокта Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган медицина оешмасының шәхси счетына тулы күләмдә күчерә.

3. Медицина оешмалары квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның бишеннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формалар буенча финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планын гамәлгә ашыру турында хисап бирә.

4. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан агымдагы финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешен бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен җибәрүгә ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш, хисап елыннан соң килә торган елның 25 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Агымдагы финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешен бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен җибәрүгә ихтыяҗ булган очракта, медицина оешмасы, хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына финанс белән тәэмин итү чыганагы агымдагы финанс елының 1 гыйнварына субсидиянең файдаланылмый калган өлеше булып торган, үтәлмәгән йөкләмәләр барлыгы турында мәгълүмат, шулай ук медицина оешмасының әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуын һәм күләмен раслый торган документларны (документлар күчермәләрен) җибәрә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, медицина оешмасыннан бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, агымдагы финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешен бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җибәрүгә ихтыяҗ булу яки булмавы турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан агымдагы финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешен бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җибәрүгә ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм медицина оешмасы арасында мондый карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә килешүгә өстәмә килешү төзелә.

5. Агымдагы финанс елында финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган, медицина оешмасы тарафыннан элек башкарылган түләүләрне кире кайта-

рудан кергән керемнәр булганда, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы финанс белән тәэмин итү чыганагы медицина оешмасы тарафыннан элек башкарылган түләүләрне кире кайтару акчасы булып торган, үтәлмәгән йөкләмәләре, шулай ук медицина оешмасының әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләү буенча йөкләмәләреннән тыш) булуын һәм күләмен раслый торган документлар (документлар күчермәләре) булуы турында медицина оешмасы мөрәҗәгате нигезендә бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен медицина оешмасының алардан файдалануы турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы медицина оешмасыннан мөрәҗәгать алган көннән биш эш көне эчендә бу Тәртипнең 1 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган, медицина оешмасы тарафыннан элек башкарылган түләүләрне кире кайтарудан кергән керемнәрне агымдагы финанс елында файдалану турында карар кабул итә.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органы субсидия бирү максатларының һәм шартларының үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

7. Субсидия, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча субсидия биргәндә билгеләнгән максатларның һәм шартларның медицина оешмасы тарафыннан үтәлмәве ачыкланган, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәгән очракта, медицина оешмасы тарафыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмалары тарафыннан субсидия акчасын кире кайтару сроклары бозылганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бу пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланган көннән 30 көн эчендә субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.